КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 ноябрь г.Казань № 910

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 12 октябрь, 787 нче карары белән расланган Табигый һәм техноген характердагы һәлакәтләр, башка гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешнең 1 – 4 нче пунктлары белән күздә тотылган мәсьәләләр буенча карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы һәлакәтләр, башка гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешнең 1 – 4 нче пунктлары белән күздә тотылган мәсьәләләр буенча карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 12 октябрь, 787 нче карары белән расланган Табигый һәм техноген характердагы һәлакәтләр, башка гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешнең 1 – 4 нче пунктлары белән күздә тотылган мәсьәләләр буенча карар кабул итү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип санарга;

6 нчы пунктта «капиталь ремонт чыгымнары сметасын, капиталь ремонт үткәрү вакытларын һәм аны финанслау чыганакларын» дигән сүзләрне «Россия Федерациясе Торак кодексының 190 статьясындагы 4 өлеш белән күздә тотылган тәртиптә билгеләнгән күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүнең һәм (яки) эшләр башкаруның иң чик кыйммәтеннән

чыгып, капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтүнең һәм (яки) эшләр башкаруның рөхсәт ителгән иң чик кыйммәтен» дигән сүзләргә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин